**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2024 елның «19» феврале 243 номер

# КАРАР

**«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1997 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы» нигезендә **карар бирәм**:

1. «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 1997 номерлы карарына, кушымталар нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 февралендәге 243 номерлы карарына 1 нче кушымта

«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 1997 номерлы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

1) **2.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

Рөхсәт бирү өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза:

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә;

-региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада;

2) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, ачык сервитут билгеләү турында карар;

3) төзелешкә рөхсәт;

4) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (әлеге объектны мондый тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документлары белән каралган булса);

5) линия объектын төзү, реконструкцияләү очракларыннан тыш, төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объекты урнашуын, җир кишәрлеге чикләрендә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләре урнашуын һәм җир кишәрлеген план буенча оештыруны чагылдыра торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат (төзүне гамәлгә ашыручы зат һәм төзелеш, реконструкцияләү төзелеш подряды шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырылган очракта, төзүче оешма яисә техник заказчы) тарафыннан имзаланган схема;

6) 9) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары таләпләренә (шул исәптән, эш документларына кертелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 1.3 өлеше нигезендә мондый проект документларының өлеше булып торган үзгәрешләрне исәпкә алып) туры килүе турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру каралган очракта) бәяләмәсе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган федераль башкарма хакимият органының федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вәкиле бәяләмәсе

8) «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы

Федераль закон белән билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклауның тиешле органы тарафыннан расланган мәдәни мирас объектын саклап калу буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты, бу объектны реставрацияләү, консервацияләү, ремонтлау һәм заманча куллану өчен аның җайланмаларын үткәргәндә;

12) “Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында” 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әзерләнгән капиталь төзелеш объектының техник планы.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2024 __
_ _____ номерлы карарына
2 нче кушымта

# ОБЪЕКТНЫ ФАЙДАЛАНУГА ТАПШЫРУГА РӨХСӘТ

1нче бит

| | |
|---|---|
| 1 бүлек. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт Реквизитлары | |
| 1.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт датасы <2>: | |
| 1.2. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт номеры <3>: | |
| 1.3. орган (оешма) атамасы<4>: | |
| 1.4. Үзгәрешләр яисә төзәтмәләр кертү датасы <5>: | |
| 2 бүлек. Төзүче оешма турында мәгълүмат | |
| 2.1. Физик зат яки шәхси эшмәкәр турында белешмәләр: | |
| 2.1.1. Фамилиясе, | |
| 2.1.2. Исеме: | |
| 2.1.3. Атасының исеме <6>: | |
| 2.1.4. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН): | |
| 2.1.5. ОГРНИП <7>: | |
| 2.2. Юридик зат турында белешмәләр: | |
| 2.2.1. Тулы исеме <8>: | |

| | |
|---|---|
| 2.2.2. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН): | |
| 2.2.3. Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| 3 бүлек. Капиталь төзелеш объекты турында белешмәләр | |
| 3.1. Проект документлары буенча капиталь төзелеш объектының (этапның) исеме: | |
| 3.2. Капиталь төзелеш объектына карата башкарылган эшләр төре <9> | |
| 3.3. Капиталь төзелеш объектының адресы (урыны <10> | |
| 3.3.1. Россия Федерациясе субъекты: | |
| 3.3.2. 3.3.2. Россия Федерациясе субъекты составындагы муниципаль район, муниципаль округ, шәһәр округы яисә шәһәр эчендәге территория (федераль әһәмияттәге шәһәрләр өчен), федераль территория | |
| 3.3.3. 3.3.3. муниципаль район составындагы (муниципаль район өчен) яисә шәһәр округының шәһәр эчендәге районы составындагы шәһәр яки авыл җирлеге (федераль территорияләрдә урнашкан биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан тыш): | |
| 3.3.4. Торак пунктның төре һәм исеме: | |
| 3.3.5. Планлаштырылган структура элементының исеме: | |
| 3.3.6. Урам-юл челтәре элементы исеме | |
| 3.3.7. Бинаның тибы һәм номеры: | |
| 4 бүлек. Җир кишәрлеге турында мәгълүмат | |
| 4.1. Капиталь төзелеш объекты урнашкан җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) кадастр номеры 11 | |

| | |
|---|---|
| 5 бүлек. Аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү башкарылган төзелешкә бирелгән рөхсәт турында белешмәләр | |
| 5.1. Төзелешкә рөхсәт датасы: | |
| 5.2. Төзелешкә рөхсәт номеры: | |
| 5.3. Төзелешкә рөхсәт биргән орган (оешма) исеме: | |
| 6 бүлек. Капиталь төзелеш объектының факттагы күрсәткечләре һәм техник план турында белешмәләр <12> | |
| 6.X. Проект документациясендә каралган капиталь төзелеш объектының исеме <13>: | |
| 6.X.1. Капиталь төзелеш объектының төре <14>: | |
| 6.X.2. Объектның билгеләнеше <15>: | |
| 6.X.3. Реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының кадастр номеры 16 | |
| 6.X.4. Төзелеш мәйданы (кв. м) <17>: | |
| 6.X.4.1. Капиталь төзелеш объектының бер өлешен төзү мәйданы (кв. м) <18>: | |
| 6.X.5. Мәйданы (кв. м) <19>: | |
| 6.X.5.1. Капиталь төзелеш объекты өлешенең мәйданы (кв. м) <20>: | |
| 6.X.6. Торак булмаган биналарның мәйданы (кв. м): | |
| 6.X.7. Торак биналарның гомуми мәйданы (балконнар, лоджий, веранд һәм террасны исәпкә алып) | |
| (РФ Төзелеш министрлыгының 2022 елның 2 сентябрендәге 711/пр номерлы боерыгы редакциясендә)) | |

| | |
|---|---|
| 6.X.7.1. Торак биналарның гомуми мәйданы (балконнар, лоджий, веранда һәм террасалардан тыш) | |
| (РФ Төзелеш министрлыгының 2022 елның 2 сентябрендәге 711/пр номерлы боерыгы редакциясендә)) | |
| 6.X.8. Бүлмәләр саны (данә): | |
| 6.X.9. Торак булмаган биналар саны (данә): | |
| 6.X.10. Торак биналар саны (данә): | |
| 6.X.11. шул исәптән фатирлар (данә): | |
| 6.X.12. Машина урыннары саны (данә): | |
| 6.X.13. Катлар саны: | |
| 6.X.14. шул исәптән җир асты катлары саны: | |
| 6.X.15. Сыйдырышлыгы (кеше): | |
| 6.X.16. Биеклеге (м): | |
| 6.X.17. Энергетика нәтиҗәлелеге классы (булган очракта) <21>: | |
| 6.X.18. Башка күрсәткечләр <22>: | |
| 6.X.19. Техник планны әзерләү датасы: | |
| 6.X.20. Техник планны әзерләгән кадастр инженерының индивидуаль шәхси счетының иминият номеры: | |
| 7 бүлек. Линия объектының факттагы күрсәткечләре һәм техник план турында белешмәләр 23 | |
| 7.X. Проект документларында каралган линия объекты исеме <24>:: | |

| | |
| --- | --- |
| 7.X.1. Реконструкцияләнгән линия объектының кадастр номеры: | |
| 7.X.2. Озынлыгы (м) <25>: | |
| 7.X.2.1. Кишәрлекнең яки линияле объектның бер өлешенең озынлыгы (м) 26 | |
| 7.X.3. Категория (класс): | |
| 7.X.4. Егәрлек (үткәрү сәләте, йөк әйләнеше, хәрәкәт ешлыгы): | |
| 7.X.5. Төре (электрүткәргеч кабель линиясе, электрүткәргеч һава линиясе, электрүткәргеч кабель-һава линиясе), электрүткәргеч линияләренең киеренкелек дәрәҗәсе: | |
| 7.X.6. Башка күрсәткечләр <27>: | |
| 7.X.7. Техник планны әзерләү датасы: | |
| 7.X.8. Техник планны әзерләгән кадастр инженерының индивидуаль шәхси счетының иминият номеры: | |

| | | |
| --- | --- | --- |
| Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы органның (оешманың) вәкаләтле заты вазифасы | имза | инициаллар, фамилия |

<1> Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасының тулысынча тутырылмаган (буш) кисәкләре гариза бирүчегә бирелә торган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт составына кертелми. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасын тутырганнан һәм аны комплектлаштырганнан соң объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең һәр битендә өске уң почмагында «___ бит» кыры куела, анда 1 дән башлап, битнең тиешле тәртип номеры күрсәтелә.
<2> Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү датасы күрсәтелә. Дата ДД.ММ.ГГГГ форматында гарәп цифрлары белән күрсәтелә. Монда хәрефләр түбәндәгеләрне белдерә: ДД – көн, ММ – ай, ГГГГ – ел. Шул ук вакытта көн һәм (яки) ай бердән алып тугызга кадәр ике сан белән күрсәтелә.

<3> объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан бирелгән, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең А-Б-В-Г структуралы номеры күрсәтелә:

А - территориясендә төзелгән (реконструкцияләнгән) капиталь төзелеш объекты урнашкан кадастр округы номеры (ике урынлы). Объект ике һәм аннан да күбрәк кадастр округы территориясендә урнашкан очракта, «0» номеры күрсәтелә;

Б – территориясендә төзелгән (реконструкцияләнгән) капиталь төзелеш объекты урнашкан кадастр районы номеры. Объект ике һәм аннан күбрәк кадастр районы территориясендә урнашкан очракта, «0» номеры күрсәтелә;

В – объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан бирелгән объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең тәртип номеры;

Г – объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтне бирү елы (тулысынча).

Номерның состав өлешләре бер-берсеннән " - " билгесе белән аерылып тора. Цифрлы индекслар гарәп цифрлары белән билгеләнә.

Федераль башкарма хакимият органнары, «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе өчен номер ахырында мондый орган, оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә торган шартлы тамга күрсәтелә (булган очракта).

4 Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы Федераль башкарма хакимият органы яки Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы, яисә җирле үзидарә органы исеме, яки объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы оешманың исеме күрсәтелә: «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе яисә «Роскосмос» космос эшчәнлеге буенча дәүләт корпорациясе.

5 Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәткә үзгәрешләр керткән, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәттә җибәрелгән хаталарны һәм (яисә) ялгышларны төзәткән очракта, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәткә үзгәрешләр кертү яисә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәткә төзәтмәләр кертү турында вәкаләтле орган (оешма) тарафыннан соңгы карар кабул итү датасы күрсәтелә. Капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү датасы үзгәрми.

<6> Атасының исеме булган очракта күрсәтелә.

<7> Төзүче шәхси эшмәкәр булган очракта тулылана.

8 Төзүче оешма юридик зат булып торган очракта, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 54 статьясы (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1994, №32, 3301 статья; 2015, №27, 4000 статья) нигезендә оешманың тулы исеме күрсәтелә.

9 Аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү (реконструкцияләү) гамәлгә ашырылган төзелешкә рөхсәт буенча күрсәтелә.

<10> 3.3.1 - 3.3.3.7 юлларда капиталь төзелеш объектының адресы күрсәтелә, ә булмаганда - тиешле юлларны тутыру юлы белән капиталь төзелеш объектының урнашу урыны күрсәтелә; линия объектлары өчен, территориясендә шундый линия объектын төзү гамәлгә ашырылган Россия Федерациясе субъект(-лар)ы һәм муниципаль берәмлек(ләр) исеме рәвешендә урнашу урыны күрсәтелә. Линия объектларын реконструкцияләгән очракта, мондый линия объектын

реконструкцияләү гамәлгә ашырылган Россия Федерациясе субъекты (субъектлары) һәм муниципаль берәмлек (берәмлекләр) исеме рәвешендә урнашкан урыны күрсәтелә.

Капиталь төзелеш объектының адресы яисә урнашу урыны турындагы мәгълүматлар Планлаштыру структурасы элементлары, урам-юл челтәре элементлары, адрес реквизитлары сыйфатында кулланыла торган адресация объектларының элементлары, биналарның (корылмаларның), бүлмәләрнең типлары исемлеге һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2015 елның 5 ноябрендәге приказы белән расланган Адрес барлыкка китерүче элементларның кыскартылган исеме кагыйдәләре нигезендә тутырыла. 171н номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге приказлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр (2015 елның 10 декабрендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан теркәлгән, теркәү номеры 40069). N 207н (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2018 елның 8 ноябрендә теркәлгән, теркәү N 52649), 2019 елның 17 июнендә. N 97н (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2019 елның 10 июлендә, теркәү N 55197), 2020 елның 10 мартында теркәлде. №38н (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2020 елның 16 апрелендә, теркәү N 58121), 2021 елның 23 декабрендә теркәлгән. N 220н (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2022 елның 3 февралендә теркәлгән, теркәү N 67143).

<11> Проект документларында каралган барлык, шул исәптән мөлкәт комплексы, бердәм күчемсез комплекс яки катлаулы объект буларак предприятие составына яки катлаулы объект (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) составына керүче капиталь төзелеш объектларына карата тутырыла. Линия объектына мөнәсәбәтле объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт биргәндә, тутыру мәҗбүри булып тормый.

12 Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең 6 бүлегендәге юллар проект документларында каралган, шул исәптән милек комплексы, бердәм күчемсез милек комплексы буларак предприятие составына яисә катлаулы объект (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) составына керүче файдалануга тапшырыла торган һәр капиталь төзелеш объектына карата тутырыла.

13 6.X - 6.X.18 юлларын тутырганда юл номерларында "X" тамгасы урынына объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан проект документларында каралган, шул исәптән милек комплексы, бердәм күчемсез милек комплексы буларак предприятие составына яисә катлаулы объект (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) составына керә торган һәрбер объектка карата 1 дән башлап бердәм нумерация бирү ярдәмендә әлеге юллар күрсәткече кайсы капиталь төзелеш объектына караса, шул объектның тәртип номеры күрсәтелә. Әгәр проект документларында бер объектны төзү, реконструкцияләү каралган булса, 7.X юлында зурлык тутырылмый.

<14> Капиталь төзелеш объектларының бер төре күрсәтелә: бина, төзелмә, корылма.

<34> 2015 елның 13 июлендәге Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлешенең 9 пунктында каралган объектны билгеләү күрсәтелә. "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" 218-ФЗ номерлы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, N 29, 4344; 2021, N 15, 2446) төзелешкә рөхсәт әзерләү датасына.

16 Реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының кадастр номеры күрсәтелә. Мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкарганда, мондый объект ныклылыгының һәм куркынычсызлыгының конструктив һәм башка характеристикаларына үзгәрешләр кертелгән очракта, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында исәпкә алынган мәдәни мирас объектының кадастр номеры күрсәтелә.

17 Файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә, ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап) файдаланырга мөмкин булган капиталь төзелеш объектының төзелеш, реконструкция өлеше булып торган төзелеш, реконструкция этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, 6.X.4 юлында капиталь төзелеш объектының элегрәк файдалануга тапшырылган барлык этапларына туры килә торган капиталь төзелеш объекты төзелешенең һәм файдалануга тапшырыла торган этабының мәйданы күрсәтелә.

<18>Файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә, ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап) файдаланырга мөмкин булган капиталь төзелеш объектының төзелеш, реконструкция өлеше булып торган төзелеш, реконструкция этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла. 6.X.4.1 юлында файдалануга тапшырыла торган этапта төзелеш мәйданы күрсәтелә.

<19>Файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә, ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап) файдаланырга мөмкин булган капиталь төзелеш объектының төзелеш, реконструкция өлеше булып торган төзелеш, реконструкция этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, 6.X.5 юлында капиталь төзелеш объектының элегрәк файдалануга тапшырылган барлык этапларына туры килә торган капиталь төзелеш объектының һәм файдалануга тапшырыла торган этабының мәйданы күрсәтелә.

<20>Файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә, ягъни әлеге капиталь төзелеш объектының башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә (алга таба әлеге искәрмәдә – этап) файдаланырга мөмкин булган капиталь төзелеш объектының төзелеш, реконструкция өлеше булып торган төзелеш, реконструкция этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла. 6.X.5.1 юлында файдалануга тапшырыла торган этапның мәйданы күрсәтелә.

<21> Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар нигезендә билгеләнә торган энергетика нәтиҗәлелеге классын бирү мәҗбүри булган капиталь төзелеш объектларына карата күрсәтелә.

<22> Булганда, мондый объектның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә капиталь төзелеш объектының төп характеристикалары (күләме, тирәнлеге, урнашу тирәнлеге), шулай ук капиталь төзелеш объектының югарыда күрсәтелмәгән башка характеристикалары күрсәтелә, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкарылганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына кагылса, башка характеристикалар шулай ук мәдәни мирас объектына карата күрсәтелә.

12 Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнең 6 бүлегендәге юллар проект документларында каралган, шул исәптән милек комплексы, бердәм күчемсез милек комплексы буларак предприятие составына яисә катлаулы объект (берничә капиталь төзелеш объектыннан торган объект) составына керүче файдалануга тапшырыла торган һәр капиталь төзелеш объектына карата тутырыла.

24 7.X - 7.X.8 юлларын тутырганда юл номерларында «X» тамгасы урынына объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы орган (оешма) тарафыннан проект документларында каралган, шул исәптән милек комплексы, бердәм күчемсез милек комплексы буларак предприятие составына яисә катлаулы объект (берничә капиталь төзелеш объектыннан

торган объект) составына керә торган һәрбер линия объектына карата 1 дән башлап бердәм нумерация бирү ярдәмендә әлеге юллар күрсәткече кайсы линия объектына караса, шул объектның тәртип номеры күрсәтелә. Әгәр проект документларында бер объектны төзү, реконструкцияләү каралган булса, 7.Х юлында зурлык тутырылмый.

<25>Әлеге объектның башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә файдаланырга мөмкин булган, линия объектының төзелеш, реконструкция өлеше булып торган төзелеш, реконструкция этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта (алга таба әлеге искәрмәдә – этап), 7.Х.2 юлында мондый линия объектының элегрәк файдалануга тапшырылган барлык этапларына туры килә торган линия объектының һәм файдалануга тапшырыла торган этабының озынлыгы күрсәтелә.

Линия объекты озынлыгының үзгәрүенә китерә торган мондый линия объекты участогын (участокларын) яисә өлешен (өлешләрен) үзгәртүне күздә тоткан реконструкция ясалган линия объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, 7.Х.2 юлында линия объектының элегрәк файдалануга тапшырылган һәм файдалануга тапшырыла торган барлык участокларының яисә өлешләренең озынлыгы күрсәтелә.

<26> Әлеге объектның башка өлешләрен төзүгә яисә реконструкцияләүгә бәйсез рәвештә файдалануга тапшырылырга һәм автоном рәвештә файдаланырга мөмкин булган, линия объектының төзелеш, реконструкция өлеше булып торган төзелеш, реконструкция этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта (алга таба әлеге искәрмәдә – этап), яисә линия объекты озынлыгының үзгәрүенә китерә торган мондый линия объекты участогын (участокларын) яки өлешен (өлешләрен) үзгәртүне күздә тоткан реконструкция ясалган линия объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта тутырыла.

Әлеге очракларда 7.Х.2.1 юлында файдалануга тапшырыла торган этапның озынлыгы күрсәтелә, яисә линия объектының тиешле участогы яисә бер өлеше озынлыгы күрсәтелә.

<27> Булганда, мондый объектның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә линия объектының төп характеристикалары (күләме, тирәнлеге, урнашу тирәнлеге) күрсәтелә, шулай ук линия объектының югарыда күрсәтелмәгән башка характеристикалары күрсәтелергә мөмкин.